Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

21 гыйнвар 2020 ел                                                                                    № 05

Территорияне ызанлау проектын
әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасының техник инвентаризацияләү бюросы» акционерлык җәмгыятенә инвестиция чаралары хисабына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәрешәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Нефтебаза ур., 1й., 2 й. адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортлар белән чикләнгән территорияне ызанлау проектын эшләүгә керешергә тәкъдим итәргә. (1 нче кушымта).

2. «Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетҗитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе                                                                    Л.Ф. Вәлиев

.

Әлмәт шәһәр Башкарма
комитетының 2020 елның
«21» гыйнвар № 05 карарына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәрешәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Нефтебаза ур., 1й., 2 й. адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортлар белән чикләнгән территория чикләре




Башкарма комитет җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары

Д.В. Косарев